«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_____ Э.Н. Фәттахов
"6" февраль 2015 нче ел

ТАТАР ТЕЛЕ

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының
татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына
2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тестларын
үткәрү материалларының үзенчәлекләре
(спецификация)

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен 2015 елда татар теленнән бердәм республика тестларын үткәрү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

1. Бердәм республика тестларын үткәрү материалларының әһәмияте

Бердәм республика тестларын үткәрү рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларның татар теленнән әзерлек дәрәҗәләрен бәяләүне күздә тота.

2. Бердәм республика тестларын үткәрү материаллары эчтәлеген билгели торган документлар

Бердәм республика тестларын үткәрү материаллары түбәндәге документка нигезләнеп эшләнә:

Харисова Ч.М., Фәтхуллова К.С., Хәбибуллина З.Н. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2011. – 239 б.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле: үрнәк гомуми программа V – IX сыйныфлар /Төзүчеләр: Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Г.Р.Шакирова // http://mon.tatarstan.ru/rus/programmy.htm?page=2

3. Бердәм республика тестларын үткәрү материалларының төзелешен эшләү, эчтәлегенә мәгълүматлар сайлау

Эш укучыларның лингвистик компетенциясен тикшерә: тел һәм сөйләм турындагы белемнәр; тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алу; шулай ук тану, аеру, фикер йөртү осталыклары һәм күнекмәләрне. Формалашкан тел компетенциясе дәрәҗәсе турында укучыларнын тел нормаларын (лексик, грамматик, стилистик, орфографик, пунктуацион) үтәү белән бәйле осталыклары һәм күнекмәләре хәбәр итә. Коммуникатив компетенция эштә укучыларның сөйләм эшчәнлегенең нәтиҗәле һәм рецептив күнекмәләренә ия булуы дәрәҗәсе тикшерү белән ачыклана.

Бердәм республика тестларын үткәрү материалларындагы биремнәр тупланмасы укучыларның әзерлек дәрәҗәсен бәяләргә ярдәм итә.

Бердәм республика тестларын үткәрү материаллары сайлап алу мөмкинлеген истә тотып төзелгән: укучы ике сочинениенең берсен сайлап алып яза.

Аерым биремнәрне һәм тестны гомумән бәяләү системасы педагогик үлчәүләр теориясе һәм практикасы таләпләрен һәм татар телен укыту традицияләрен истә тотып эшләнде.

4. Бердәм республика тестларын үткәрү материалларының төзелеше һәм эчтәлеге

Бердәм республика тестларын үткәрү материалларының һәр варианты ике өлештән гыйбарәт һәм формасы, катлаулылык дәрәҗәсе белән асрылып торган 21 биремне үз эченә ала.

1 нче бүлек (1–20) – кыска җаваплы биремнәр.

2 нче бүлек (21) – укылган текст нигезендә үз фикереңне белдерә алуны тикшерүгә юнәлдерелгән киңәйтелгән җаваплы ачык типтагы бирем.

Биремнәрнең чагылышы 1 нче таблицада бирелә.

1 нче таблица. Биремнәрнең чагылышы

Эшнең өлешләре	Биремнәрнең саны	Башлангыч (максималь) иң югары балл	Биремнәрнең торләре (типлары)
1 нче бүлек	20 (1-20 нче биремнәр)	20	Кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр
2 нче бүлек	1 (21 нче бирем)	9	Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәр
2 нче бүлек		Грамоталылык һәм сөйләм төгәллеге өчен 10 балл	
Барлыгы	**21**	**39**	

5. Бердәм республика тестларын үткәрү материалларын эчтәлекләре һәм эш төрләренә нигезләнеп бүлү

Әлеге бүленеш 2 нче таблицада күрсәтелгән

2 нче таблица. "Татар теле" предметының төп бүлекләрендәге биремнәрнең бүленеше

Бүлекләр	Биремнәр саны	Иң югары башлангыч балл	39 баллга тигез булган иң югары башлангыч баллдан биремнәрнең әлеге кисәге өчен куела торган иң югары башлангыч балл процценты
Сөйләм. Уку. Язма сөйләмне адекват аңлау	1	1	2
Фонетика	1	1	2
Сүз ясалышы	1	1	2
Морфология	3	3	7
Синтаксис	5	5	13
Орфография	2	2	5
Пунктуация	4	4	12
Сөйләм матурлыгы.	3	3	7
Сөйләм. Язу. Бирелгән тема һәм сөйләмнең функциональ-мәгънәви төрле нигезендә текст төзү.	1	9	23
Грамоталылык һәм сөйләм төгәллеге	2 нче бүлек	10	27
Барлыгы	21	39	100

Бердәм республика тестларын үткәрү материаллары тел материалын бирү ысуллары ягыннан бик төрле (3 нче таблица). Укучы текст эчендә кулланылган тел күренешләрен белән эш итә; башлангыч текстта күтәрелгән проблемага, тасвирланган вакыйгага карата үз фикерен белдерә.

3 нче таблица. Тел материалы белән эшләү төрләре ягыннан тест биремнәренең бүленеше

Тел материалы белән эш төрләре	Биремнәр саны	Иң югары башлан-гыч балл	39 баллга тигез булган иң югары башлангыч баллдан чыгарылган тел материалы белән эшләүнең төрләрен чагылдыра торган биремнәрне үтәгән өчен куелган иң югары балл процценты
Текст белән эшләү: текстта бирелгән тел күренешләре белән	20	20	50

эшләү (текстка тел ягыннан анализ)			
Сочинение язу	1	9	23
Грамоталылык		10 (сочинение язу нигезендә)	27
Барлыгы	21	39	100

6. Бердәм республика тестларын үткәрү материалларын катлаулылыгы дәрәҗәсеннән чыгып бүлү

Бердәм республика тестларын үткәрү материалларының катлаулылык дәрәҗәсе ягыннан бүленеше 5 нче таблицада күрсәтелгән.

5 нче таблица. Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше

Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе	Биремнәрнең саны	Иң югары башлангыч балл	64 баллы иң югары башлангыч баллдан чыгып, биремнәрнең әлеге кисәгә өчен куелган иң югары башлангыч балл %
Нигез (базовый)	20	30	84
Югары	1	9	16
Барлыгы	21	39	100

7. Эшне башкару вакыты

Бердәм республика тестларын үткәрү өчен, 150 минут вакыт бирелә.

8. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар

Татар теле буенча бердәм республика тестларын үткәргәндә, орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

9. Аерым биремнәрне һәм эшне тулаем бәяләү системасы

1 нче бүлектәге һәр дөрес үтәлгән бирем өчен 1 балл куела. Дөрес җавап яки җавап бөтенләй булмаса, 0 балл куела. 1 нче бүлек биремнәрен дөрес эшләгән укучы ала алган иң югары балл – 20.

2 нче бүлек биремнең җавабы махсус эшләнгән критерийлар буенча тикшерелә. Уңышлы башкарган укучыга куела торган иң югары балл – 9.

Укучының грамоталылыгын һәм язма сөйләменең төгәллеген бәяләү сочинение тикшерү нигезендә башкарыла, 10 югары балл куела.

10. Бердәм республика тестларын үткәрү шартлары (белгечләргә таләпләр)

Татар теленнән бердәм республика тестлары махсус пунктларда уздырыла. Әлеге пунктлар гомуми белем бирү учреждениеләре базасында оештырыла.

Татар теленнән бердәм республика тестлары үткәрелә торган аудиториягә белгеч филологлар кертелми. Тестны татар теле һәм әдәбиятын укытмый торган педагог уздырырга тиеш.

Алга таба тест үткәрүнең тәкъдим ителгән тәртибе. Тест үткәрүнең **тәкъдим ителә торган тәртибе** түбәндәгечә.

Тест материаллары салынган пакетны алгач, укучы биремнәрне үтәячәк барлык бланкларга имзасын куя. Имза куелган бланклар укучының эш өстәленә кирәкле тәртиптә урнаштырыла һәм эш барышында тутырыла.

Шуннан соң укучылар уку өчен таратылган текст белән танышалар. Укылган текстка эчтәлекле һәм лингвистик анализ ясау белән бәйле биремнәрне эшләү тәкъдим ителә.

Бердәм республика тестының барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, <u>орфографик сүзлектән</u> файдаланырга мөмкин.

Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрнең дәреслеген бердәм республика тестларын үткәрү буенча махсус әзерлек узган татар теле белгечләре тикшерә.

11. 2014 нче ел белән чагыштырганда 2015 нче елгы үзгәрешләр

Гомумән эшнең төп характеристикалары сакланган.

Биремнәр саны һәм беренчел балл үзгәргән.

Эштәге биремнәр хәрефләр белән түгел, ә саннар белән билгеләнгән.

Сайлап алу өчен, бер бирем (21.2) өстәлгән.

11. 2015 нче елгы бердәм республика тестларын үткәрү материаллары планы

2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тестларын үткәрүнең эчтәлеге Кушымтада китерелгән гомумиләштерелгән планда чагыла.

Кушымта

2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тестларын үткәрү материалларының гомумиләштерелгән планы

Эштә һәм җавап бланкларында биремнәрне билгеләү: А - җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, В - кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр, С - укылган текст нигезендә үз фикерен белдерә алуын тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнәр.

Биремнәрнең авырлык дәрәҗәсе: Н – нигез (база), Ю – югары.

№	Биремнең эштәге билгеләнеше	Эчтәлекнең тикшерелә торган элементлары	Эчтәлекнең тикшерелә торган элементларының коды	Тикшерелә торган күнекмәләр коды	Биремнәрнең авырлык дәрәҗәсе	Эшләнгән бирем өчен куелган иң югары балл	Биремне үтәү вакыты (мин.)
1	1	Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны тикшерү	8.1	13	Н	1	5
2	2	Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы	10.1	10.2	Н	1	5
3	3	о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы	6.2	1	Н	1	5
4	4	е, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы	6.1	1	Н	1	5
5	5	Синонимнар	2.2	3	Н	1	5
6	6	Җөмлә. Җөмләнең грамматик (предикатив) нигезе. Баш кисәкләр (ия, хәбәр)	5.2	5	Н	1	5
7	7	Гади җөмлә	5.7	17	Н	1	5
8	8	Туры һәм кыек сөйләм	5.11	17	Н	1	5
9	9	Аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре	7.5	11	Н	1	5
10	10	Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре	7.4	11	Н	1	5
11	11	Кушма җөмләгә синтаксик анализ	5.14	17	Н	1	5
12	12	Ия белән хәбәр арасында тыныш билгесе	7.1	17	Н	1	5
13	13	Гади җөмлә	5.7	17	Н	1	5
14	14	Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре	7.4	11	Н	1	5
15	15	Антонимнар. Омонимнар. Синонимнар	2.2	3	Н	1	5
16	16	Мөстәкыйль сүз төркемнәре	4.1	7	Н	1	5
17	17	Мөстәкыйль сүз төркемнәре	4.1	7	Н	1	5

18	18	Сүзнен тамыры һәм кушымчалар	3.1	15	Н	1	5.
19	19	о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы	6.2	1	Н	1	5
20	20	Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Сүзтезмә	4.1 5.1	7 16	Н	1	5
21	21	Текст турында төшенчә. Темага, максатка, адресатка 1әм сөйләм ситуациясенә бәйле тел чараларын сайлау. Сөйләм стильләре. Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы.	8.1 8.2 8.3 8.4	19 20 21	Ю	7	50

Барлык бирем – 21, шуларның катлаулылык дәрәҗәсе бусынча: Н – 20, Ю -1.
Беренчел башлангыч балл – 39.
Эшне башкару вакыты – 150 мин.